| АЛЕКСЕЕВСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ АЛЕКСЕЕВСК РАЙОН СОВЕТЫ |
|---|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

28.07.2026 п.г.т. Алексеевское № 62

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Советы депутаты статусы турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

Алексеевск районы прокуратурасының 22.05.2026 ел, №02-08-01 протестын үтәү йөзеннән, норматив хокукый актларны «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 28.12.2025 ел, № 505-ФЗ Федераль законга туры китерү максатында,

**Алексеевск муниципаль районы Советы карар бирде:**

1. «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Советы депутаты статусы турында Нигезләмәне раслау хакында» Алексеевск муниципаль районы Советының 03.11.2022 ел № 134 карары белән расланган Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Советы депутатлары статусы турында Нигезләмәнең 17 статьясындагы 1 пунктының 10 пунктчасында түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Хисап финанс елыннан соң килүче елның 30 апреленнән дә соңга калмыйча, үзенең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат гамәлдәге законнар нигезендә депутат «Дәүләт вазыйфаларын биләүче зат һәм башка затларның,чыгымнары керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 03.12.12 ел, № 230-ФЗ Федераль закон нигезендә чыгымнар турында мәгълүмат тапшыру өчен нигезләр барлыкка килгән очракта мәгълүмат тапшырырга тиеш».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алексеевск муниципаль районы Советының законлылык, регламент, җирле үзидарә һәм депутат этикасы буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

**Муниципаль район башлыгы,**
**Совет Рәисе** **С.А.Демидов**